| | | |
|---|---|---|
| УПРАВЛЕНИЕ<br>ПО ОХРАНЕ И<br>ИСПОЛЬЗОВАНИЮ<br>ОБЪЕКТОВ<br>ЖИВОТНОГО МИРА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ<br>ХАЙВАННАР ДӨНЬЯСЫ<br>ОБЪЕКТЛАРЫН САКЛАУ<br>ҺӘМ АЛАРДАН<br>ФАЙДАЛАНУ ИДАРӘСЕ |

**Приказ** **Боерык**

10.12.2015 г. Казань № 168-од

"Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендә булган, Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтендәге урынга билгеләнгән гражданнар үзенең, ә шулай ук ире (хатыны) һәм яше җитмәгән балаларының чыгымнары турында мәгълүмат бирергә тиешле, вазифалар исемлеге турында"гы 2014 елның 20 маеннан 69-од номерлы Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе боерыгына үзгәрешләр кертү турында

"Коррупциягә каршы тору сораулары буенча Россия Федерациясенең аерым канун чыгаручы актларына үзгәрешләр кертү турында"гы 2014 елның 22 декабреннән 431-ФЗ номерлы Федераль канун белән тәңгәл килеп **боерам:**

1. "Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендә булган, Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтендәге урынга билгеләнгән гражданнар үзенең, ә шулай ук ире (хатыны) һәм яше җитмәгән балаларының чыгымнары турында мәгълүмат бирергә тиешле, вазифалар исемлеге турында"гы 2014 елның 20 маеннан 69-од номерлы Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе ( алга таба – Идарә) боерыгына киләсе үзгәрешләр кертергә:

Преамбулада " Татарстан Республикасы Президенты Боерыгы белән "2013 елның 22 апреленнән УП-329 номерлы "Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтендәге урынга билгеләнгән гражданнар үзенең, ә шулай ук ире (хатыны) һәм яше җитмәгән балаларының чыгымнары турында мәгълүмат бирергә тиешле, вазифалар исемлеген раслау турында" сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктны киләсе басмада сөйләп бирергә:

«3. Идарәдәге Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә ел саен, керемнәр, милек һәм милки йөкләмәләр турында мәгълүматны тапшыру өчен билгеләнгән вакытта, мәгълүмат бирү елы алдыннан килгән (алга таба – хисап чоры) бер ел дәверендә үзенең, ә шулай ук ире (хатыны) һәм яше җитмәгән балаларының җир, бүтән күчемсез мөлкәт объектлары,транспорт чаралары, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (катнашу өлеше, оешманың устав капиталының өлешләре) алуның һәрбер килешүе буенча, үзенең, ә шулай ук ире (хатыны) һәм яше җитмәгән балаларының чыгымнары турында мәгълүматны тапшырга, әгәр дә килешүләрнең гомуми суммасы гаиләнең, килешү төзер алдыннан килгән, соңгы 3 ел эчендәге уртак кеременнән артык булса, бу килешүләрне төзү өчен алынган чараларның чыганагын күрсәтергә.”.

2. Бу боерыкның үтәлүен тикшерүне Идарә башлыгы урынбасары Ю.Б.Матвеевка тапшырырга.

Идарә башлыгы Ф.С.Батков